ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2018 Казан ш. № 5-107/тэ

«Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте күрсәтә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2019 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя куюю турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2018№ 5-107/тэ карарына кушымта

«Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2019 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="2">№ п/п</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы</th><th rowspan="2">Тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре</th></tr>
<tr><th>Су</th><th>Пар</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Казан шәһәре</td></tr>
<tr><td rowspan="3">1</td><td rowspan="3">«Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте</td><td colspan="4">Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр</td><td>-</td><td>452,97</td></tr>
<tr><td>01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр</td><td>-</td><td>455,29</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге